| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ФЕДОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ФЕДОРОВСКИЙ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26 гыйвары 2022 ел. Федоровский ав. № 41

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Советының 31 октябре 2019 елнын 25 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлегенең Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.17 статьясындагы 4 пунктының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2021 елның 01 июлендәге 244-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау турында» 31 октябре 2019 елнын 25 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлегенең Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 27 статьяның 27 пунктын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга: «Кредит (облигациядән тыш) буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә торган муниципаль гарантия кредит килешүендә (заем килешүендә) һәм (яисә) күрсәтелгән муниципаль гарантияне кредитор (заем) йөкләмәләрен бирү турындагы килешүдә күрсәтелгән кредит (заем) акчаларыннан максатчан файдалануны үз ягыннан тикшереп торуны гамәлгә ашыру шарты белән бирелә.»;

1.2. 32 статьяда:

2 пунктны түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясенең милли үсеше максатларын һәм гавами хакимият органнары эшчәнлегенең аларга ирешү юнәлешен билгели торган документлар;»;

өченче - бишенче абзацларны дүртенче - алтынчы абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://_fedor-kaybici.tatarstan.ru/ веб - адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Федоровский авыл җирлеге Башлыгы Ф.Ф.Зайнуллин